**ГЛАВА**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.11.2021 № 1 Күләгәш

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Яңа Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2021 елның 16 ноябрендә 14 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2021 елның 16 ноябрендә 15 сәг 00 мин билгеләргә.

3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:

-1 этап: Күләгәш авылының Яшьләр, Урман ур, Казан ур, Пионер урамында яшәүчеләр.

-2 этап: Күләгәш авылының Совет, Спорт урамында яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Байтуган торак пункты территориясендә, I төркем

инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- янгын сүндерү машинасын карап тоту, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт шартнамәсе буенча түләү;

- үләнне чабу (хезмәт шартнамәсе буенча түләү);

- МТЗ-82 тракторы өчен гаражны ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәт шартнамәсе буенча түләү),

- МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, юлларга хезмәт күрсәтү, кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май, запас частьләр сатып алу, хезмәт шартнамәсе буенча түләү);

- Куләгәш авылында урамнарны яктырту өчен яктырткыч лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Күләгәш авылындагы күперне Бимка елгасы аша ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу һәм шартнамә буенча түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Күләгәш авылы, Совет урамы, 38 А йорт, авыл мәдәният йорты территориясендә үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы

Совет Кулегашского сельского поселения
Күләгәш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002639

Ю.Н.ВАСИЛЬЕВ